**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

чираттан тыш утырыш
**КАРАРЫ**

16 нчы февраль 2021 ел **№ 37** Теләче авылы

Теләче муниципаль район Советының 2006 елның 14 июлендәге 48 номерлы «Теләче муниципаль районында гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Теләче муниципаль районы Советының 2006 елның 14 июлендәге 48 номерлы «Теләче муниципаль районында гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Теләче муниципаль районында гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә:

А) 3 статьяны түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Инициатив проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча гражданнардан сораштыруда уналты яшен тутырган муниципаль берәмлек халкы яисә аның өлешендә яшәүчеләр катнашырга хокуклы, анда инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә.».

Б) 7 статьяны түбәндәге эчтәлекле 3 пункт белән тулыландырырга:

«3. Инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлектә уналты яшен тутырган яшәүчеләрнең яисә аның бер өлешенең гражданнарның әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау өчен.».

В) 8 статьяның 1 пунктын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«1. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү турында карар Теләче муниципаль районы Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланырга мөмкин.

Сораштыру үткәрү турында карарда билгеләнә:

- сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары;

- сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган сорауны (мәсьәләләрне) формалаштыру;

- методика проведения опроса;

– форма опросного листа;

- сораштыруда катнашучы район халкының минималь саны;

- "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.».

Г) 22 статьяның 1 пунктын түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга: «яки муниципаль берәмлек халкын;».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов